# Өчпочмаклы солдат хатлары




**Гыйльметдинова М.Р.,**
**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы**
**18-нче «Карлыгач» катнаш төрдәге балалар бакчасы**
**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе**

5 – 7 яшьлек балалар өчен.

***Максат***:

Солдат хатлары турында белемнәрне формалаштыру. Аларның эчтәлеге, әһәмияте турында күзаллау булдыру. Солдатларның Бөек Җиңүне якынайтудагы батырлыгы белән горурлану хисләре уяту.




-Исәнмесез, балалар! Хәерле көннәр сезгә! Көннәребез якты, төннәребез тыныч!

-Ә бу көннәрне безгә бүләк итүчеләр кемнәр алар? Без нинди бөек бәйрәмне билгеләп үтәргә әзерләнәбез? *(Бөек Җиңүнең 70 еллыгы эмблемасы күрсәтелә.)*

-Әйе, Бөек Ватан сугышы тәмамлануның 70 еллыгы бәйрәмен. Бу Җиңү безнең халкыбызга жиңел генә бирелмәгән.

- Бөек Ватан сугышы кайчан башланган?

-Әйе, 1941 елда гитлерчылар илебезгә кисәтмичә басып керделәр. *(Сугыш сурәтләнгән рәсемнәр күрсәтелә.)* Сугышчылар, туган йортларыннан, сөйгән ярларыннан аерылып, фронтка киттеләр. Сугыш күпме кешеләрне, гаиләләрне, балаларны газизләреннән, туган якларыннан аерды. Алар бер-берләреннән бик тә, бик тә еракта иделәр.





-Балалар, сезнең дә бит читтә яшәүче дусларыгыз, туганнарыгыз бар. Сез алар белән ничек аралашасыз? (Телефон, интернет челтәре аша).


-Сугыш чорында бу мөмкинлекләр булмаган, ә алар дуслары, туганнары белән ничек аралаштылар микән? (Хатлар аша).


-Әйе, хатлар аша. Өчпочмаклы солдат хатлары... Бөек Ватан сугышы чорында солдатларны туган җире, туган өе, туганнары, балалары, сөйгән кешесе белән шушы өчпочмаклы хатлар бәйләп торган. Сугыш тынып торган арада сугышчылар кечкенә генә кәгазь битенә үзләренең исәнлекләрен белдертеп хатлар язганнар.

Тезгә куеп сезгә хатлар язам
Сугыш тынган алсу таңнарда.
Балаларым, сезне үбеп калам,
Сәлам сезгә - сөйгән ярларга.

*(Солдат хатлары турында җыр тыңлау.)*

-Хатлар... Өчпочмаклы солдат хатлары... Кайнар тир, әче күз яшьләре һәм дары исе сеңгән хатлар. Аерылу хисләрен җиңеләйткән, яшәргә көч өстәгән хатлар. Фронттан килгән хатларның кайберләре безнең көннәргә кадәр сакланган. Кәгазе таушалып, язуы танымаслык хәлгә килгән хатлар... *(Тәрбияче фронттан килгән хатлар белән таныштыра.)*





Минем кулда чып-чын яу кырыннан газиз туганнарына язылган өчпочмаклы солдат хаты. Ул моннан 70 ел элек язылган. Бу хат Бондюг районы (хәзерге Менделев районы) Абалач авылында яшәгән Галеевлар гаиләсенә юлланган. Хат гарәп хәрефләре белән язылган. Бу хатлар нинди генә телдә язылмасыннар, аларның эчтәлекләре бер: “Туган илгә Җиңү алып кайту!”




Ә бу хат 1943 елның 7 нче сентябрьдә язылган. Ул Менделеев районы Абалач авылында яшәгән Галлямовлар гаиләсенә юлланган. Хатның эчтәлеге болай: «Исәнмесез әни, Гөлсем. Мин сезгә үземнең красноармейский сәламнәремне кечкенә булган хатым аша бүләк итәмен. Хәзергә исән-сау гына хезмәт итеп ятамын. Әле сезләрне дә шулай ук дип беләмен. Әни минем өчен кайгырмагыз. Авылда нинди яңалыклар бар, ранный булып кайтучылар юкмы? Арыш-сабак ураклары урылып беттеләрме соң әле. Бәрәңгеләр дә казый башлагансыздыр инде. Мине сораучыларга ялкынлы сәлам.

Хуш-сау булыгыз.

1943ел 7 сентябрь.




Хатлар, хатлар саргайганнар
Аямаган сезне еллар.
Тик шулай да җуелмаган
Иң кадерле изге юллар.

- Ә без исә, бу хатларны укып, авыр сугыш елларын искә төшерәбез, сугышчыларның нинди батырлыклар эшләвен, ниләр кичерүен аңлыйбыз.



**Ял минуты “Тынлык! Салют!”.**

-Ә хәзер әйдәгез ял итеп алыйк. Ял минутыбыз “Тынлык! Салют!” дип атала. Мин “Тынлык!” дип әйткәч, сез тыныч кына чүгәлисез, ә “Салют” сүзен ишетүгә, сикереп торасыз, кулларыгызны югары күтәрәсез һәм өч тапкыр “Салют!” дип әйтәсез. *(Күнегүләр музыка астында ясала.)*




-Нинди авырлыклар, батырлыклар белән безнең илебез Җиңү яулап алды. Сугыш кырында күрсәткән батырлыклары өчен 7 миллионнан артык кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнгән, бик күп сугышчылар Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган. Илебезнең азатлыгы өчен һәлак булганнар истәлегенә бик күп һәйкәлләр салынган. *(Советлар Союзы Геройлары, һәйкәлләр рәсеме күрсәтелә.)*




-Бөек Ватан сугышыннан соң, Сталинград (хәзерге Волгоград) шәһәрендә “Солдат кыры” дигән урында өчпочмаклы солдат хатларына да һәйкәл куелган. *(Һәйкәл рәсеме күрсәтелә.)* Ул һәйкәлгә гвардия майоры Д.А.Петраковның кызына язылган хатынннан түбәндәге өзек китерелә: “Кара күзкәем, Мила! Сиңа күкчәчәк җибәрәм. Күз алдына китерәсеңме? Сугыш бара. Әйләнә-тирәмдә дошман снарядлары. Һәр тарафта бомба чокырлары. Шунда ук күкчәчәк үсеп утыра. Чираттагы шартлау. Чәчәк өзелде. Мин аны алып гимнастерка кесәсенә салам. Кояшка омтылган бу чәчәкне шартлау дулкыны өзде. Әгәр мин алмасам, аны таптап үтәчәкләр иде.

Мила! Әтиең Дима соңгы тамчы канга, соңгы сулышынача фашистлар белән сугышачак. Алар сине дә шушы чәчәк хәленә калдырмасыннар өчен сугышам”.



- Окоплардан килгән бу ядкарьләр хәзер безгә, сугышны күрмәгән буынга, үткән дәһшәтле сугыш елларын күз алдына китерергә, тарихны онытмаска, тыныч тормышның кадерен белергә өнди. Җиңү алып килгән батырлар безнең йөрәкләрдә мәңге саклансын! Бөек Җиңү бәйрәмендә аларны котларга язсын иде.

# Бөек Җиңү! 70 ел



